Республика яшьләр vзәгендә масштаблы проектка старт бирелде - бирелдә яшь ата-аналар очен мәктәп ачылды.      Беренче дәрес мәктәп туклануы һәм анын укучыларнын сәламәтле-ген саклаудагы роле темасына багышланды. Әйтеп китәргә кирәк, Мордовиянен мәктәптә туклануны оештыру дәрәжәсе буенча Россия тобәкләре арасында лидерлар рәтендә. Республиканын казанышлары федераль дәрәжәдә кvп тапкырлар югары бәя алды, бу жирле белгечләрнен компетентлы булуын һәм кулланыла торган алымнарнын уйланылган булуын раслый.
- Без яшь ата-аналарнын актуаль ихтыяжларыннан чыгып эш иттек; нәкъ менә алар безнен лекцияләр тематикасы нигезенә яттылар. Катнашучылар дәресләрдә алачак барлык белемнәрне кондәлек тормыш практикасында куллана алачаклар, - ди Мордовиядә «Балачак навигаторлары» Ботенроссия проектынын ата-аналар берлеге белән эшләv буенча белгеч София Колесникова.
Инициатива тобәкнен остен-лекләрен билгеләvдә аеруча әһә-мияткә ия. Мордовия Главасы Артём Здунов Россия Федерациясе Дәvләт Советынын мәктәп туклануы мәсьәләләре комиссиясенен эш торкемен житәкли, ә агымдагы ел республикада Сәламәтлек елы дип игълан ителде. Болар барысы да проектка остәмә әһәмият бирә һәм анын заманча жәмгыять очен актуальлеген ассызыклый.
- Мәктәптә туклану темасы бик актуаль һәм ата-аналар арасында кирәкле. Бvген без ачык диалог оештырабыз: безнен эксперт кинәшләр һәм ата-аналарнын сорауларына жавап бирәчәк, - ди «Балачак навигаторлары» Ботенроссия проектынын тобәк координаторы вазифаларын башкаручы Юлия Шеворакова.
Беренче дәрескә 60 тан артык кеше жыелган, ә бу исә мондый белем бирv мәйданчыгынын кирәклеген ачык кvрсәтә. Мәктәп ата-аналар очен, шулай ук баланы планлаштыручылар яки котvчеләр очен ышанычлы терәк булырга, аларга яна рольгә ияләшергә ярдәм итәргә тиеш. Проект кысаларында катнашучылар ата-аналарнын топ аспектлары белән танышып кына калмыйча, тәжрибәле экспертлардан һонәри консультацияләр алачак, шулай ук балалар тәрбияләv һәм кайгырту белән бәйле ин дулкынландыргыч сорауларга жавап табачак.
- Никита улыма тиздән сигез яшь тула. Унсигезенче мәктәптә укый - ана барысы да бик ошый, ул тырыша һәм отличник булыр дип ометләнәм. Без яшь әти-әниләр, икебез дә эшлибез. Мәктәп ашханәләрендә ашауның ничек оештырылуын белv бик кызык, - дип vз тәэсирләре белән уртаклаша ата-аналар мәктәбе тынлаучысы Алексей Поляков.
Дәрес ачык диалог форматында узды. Катнашучылар лекцияне тынлап кына калмадылар, ә актуаль мәсьәләләр буенча фикер алышуга да кушылдылар.